КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 14 февраль г.Казань № 128

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыру турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1099 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында халыкның җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган яңа туган балалы гаиләләрне балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итү буенча «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыруга бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыру турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1099 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 17 декабрь, 1157 нче, 2021 ел, 19 февраль, 88 нче, 2021 ел,

8 декабрь, 1205 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында халыкның җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган яңа туган балалы гаиләләрне балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итү буенча «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыруга бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«финанс белән тәэмин итү чыганагы арта барган нәтиҗә белән төзелә торган субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап, хисап елының I - III кварталлары өчен хисап кварталыннан соң килүче көннең 15 эш көненнән дә соңга калмыйча, хисап елының IV кварталы өчен - хисап елыннан соң килүче елның 10 февраленнән дә соңга калмыйча;»;

5.1 пунктының икенче абзацында «Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органнары» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин